ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.01.2021 г. Заинск № 38

**«2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын раслау турында**

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 29 декабрендәге 2496 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, милли-мәдәни традицияләрне һәм халык иҗатын торгызу, саклап калу һәм үстерү, мәдәни мирасны саклау, рухи-әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү, Зәй шәһәренең һәм Зәй муниципаль районының мәдәни потенциалын үстерү максатларында, «Мәдәният турында» 1998 елның 03 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын расларга (кушымта).
2. «2016-2020 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 04 мартындагы 342 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Р.Н. Камалова
8(85558) 70082

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.01.2021 ел
38 номерлы каарарына
кушымта.

| «2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы<br><br>Программаның паспорты | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2023 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы |
| Муниципаль заказчы (координатор) | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ |
| Норматив-хокукый актлар | «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары,<br>«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы законы,<br>«2014 - 2025 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары,<br>Зәй муниципаль районы Уставы |
| Программаның максаты һәм бурычлары | Максат:<br>Мәдәният тармагын комплекслы үстерү, Зәй муниципаль районының мәдәни интеллектуаль потенциалын тормышка ашыру һәм мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту, аның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү.<br>Бурычлар: |

| | |
|---|---|
| | 1. Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак, иҗтимагый-мәдәни функцияләрне башкару өчен уңай шартлар тудыру максатларында музейны комплекслы үстерү.<br>2. Гражданнарга конституциячел хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган китапханә хезмәте системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу.<br>3. Зәй муниципаль районында кинофильмнарны прокатка алу һәм күрсәтү өчен тиешле шартлар тудыру.<br>4. Халыкның барлык катламнары өчен мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрдән файдалану һәм халык иҗатына ярдәм итү өчен уңайлы шартлар тудыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2023 еллар. Программа бер этапта тормышка ашырыла. |
| Программаны үтәүчеләр | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ;<br>«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБУК;<br>«Зәй туган як тарихын өйрәнү музее» МБУК;<br>ТР ЗМР МБ Киноучреждениесе;<br>«Район мәдәният йорты» МБУК;<br>ТР ЗМР «Энергетик» Мәдәният сарае» МБУ |
| Ярдәмче программаларның исемлеге | 1. "2021-2023 елларга музей эшен үстерү" ярдәмче программасы<br>2. "2021-2023 елларга китапханә эшен үстерү" ярдәмче программасы<br>3. "2021-2023 елларга киноучреждениене үстерү" ярдәмче программасы<br>4. "2021-2023 елларга мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрне үстерү һәм халык иҗатына ярдәм итү" ярдәмче программасы |
| Елларга бүлеп һәм чыганагын күрсәтеп, финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 385163,3 мең сум тәшкил итә, шул исәптән: җирле бюджеттан 367133,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 18030,0 мең сум, елларга бүлгәндә:<br>– 2021 елда барлыгы 135121,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 129111,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 6 010,0 мең сум;<br>– 2022 елда барлыгы 127121,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 121111,1 мең сум, |

| | |
|---|---|
| | бюджеттан тыш чыганаклардан 6010,0 мең сум;<br>– 2023 елда барлыгы 122921,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 116911,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 6010,0 мең сум.<br>Программаны гамәлгә ашыруга тотыла торган акчаларның күләме ел саен бюджетны үтәү барышында ачыклана һәм 2021 - 2023 елларга бюджет формалаштырганда исәпкә алына. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре һәм программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2023 елга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Музей эшчәнлеге өлкәсендә:<br>• музейның дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган төп фонды предметлары санын ел ахырына, елына 50 берәмлеккә арттырырга;<br>• төп фондтагы предметларның гомуми санына карата актив күрсәтүгә җәлеп ителгән төп фондның музей предметлары чагыштырма санын 34 процентка арттырырга;<br>• музейга килүчеләр санын ел саен 6000 кешегә кадәр арттырырга;<br>• музейга йөрүче ташламалы категориядәге гражданнар һәм физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар санын хисап чорында база чорына карата 106 процентка арттырырга;<br>• Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына кертелгән музей предметлары өлешен 30 процентка арттырырга.<br>Китапханә эшчәнлеге өлкәсендә:<br>• басмаларга үзәкләштерелгән язылу өчен җирле бюджетта каралган акчаларны ел саен 400,0 мең сум күләмендә саклап калырга;<br>• база чоры белән чагыштырганда электрон каталогтагы язмалар санын 119 процентка кадәр арттырырга;<br>• ел саен үткәрелә торган китапханә чаралары санын 1600 берәмлеккә кадәр арттырырга;<br>• Квалификация күтәргән белгечләрнең өлешен система белгечләренең гомуми санының 31 процентына кадәр җиткерергә (арта барган нәтиҗә).<br>Киноучреждение эшчәнлеге өлкәсендә:<br>• тематик киночаралар санын арттырырга, 258 берәмлеккә кадәр.<br>• ел дәвамында күрсәтелә торган премьера фильмнары санын саклап калырга, 118 берәмлек. |

| | |
|---|---|
| | • киносеансларга йөрүчеләр санын арттырырга, 27984 кешегә кадәр.<br>Мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр эшчәнлегендә:<br>• мөмкинлекләре чикләнгән затлар катнашындагы мәдәни-ял чаралары санын арттырырга, 3140 берәмлеккә кадәр.<br>• Халыкара, Бөтенроссия, республика, район фестивальләре һәм конкурслары лауреатлары булган балалар һәм яшьләр үзешчән халык иҗаты коллективлары санын саклап калырга - 12 берәмлек.<br>• балалар һәм яшьләр өчен оештырылган мәдәни-ял чаралары санын арттырырга, 4550 берәмлеккә кадәр.<br>• уздырылган семинарлар, консультацияләр санын саклап калырга - ел саен 9 берәмлек.<br>• халык бәйрәмнәре, иҗат ярминкәләре санын арттырырга, ел саен 11 берәмлек.<br>• Халык бәйрәмнәрендә, иҗат ярминкәләрендә катнашучылар санын 71417 кешегә кадәр арттырырга. |

## Программаны гамәлгә ашыруны финанслар белән тәэмин итү

**мең сумн.**

| **Ярдәмче программаның исеме** | **Барысы** | | **2021 ел** | | **2022 ел** | | **2023 ел** | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Җирле бюджет | Бюджеттан тыш | Җирле бюджет | Бюджеттан тыш | Җирле бюджет | Бюджет тан тыш | Җирле бюджет | Бюджет тан тыш |
| «2021-2023 елларга музей эшен үстерү» | 16311,9 | 150,0 | 5437,3 | 50,0 | 5437,3 | 50,0 | 5437,3 | 50,0 |
| «2021-2023 елларга китапханә эшен үстерү» | 74211,3 | 90 | 28737,1 | 30,0 | 23737,1 | 30,0 | 21737,1 | 30,0 |
| «2021-2023 елларга киноучреждениене үстерү» | 13564,0 | 14340,0 | 5188,0 | 4780,0 | 4188,0 | 4780,0 | 4188,0 | 4780,0 |
| «Мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрне үстерү һәм 2021-2023 елларга халык иҗатына ярдәм итү» | 261046,1 | 3450,0 | 89748,7 | 1150,0 | 87748,7 | 1150,0 | 85548,7 | 1150,0 |
| **Барлыгы** | **367133,3** | **18030,0** | **129111,1** | **6010,0** | **121111,1** | **6010,0** | **116911,1** | **6010,0** |
| **БАРЫСЫ** | **385163,3** | | **135121,1** | | **127121,1** | | **122921,1** | |

## I Программаны хәл итүгә юнәлтелгән проблеманы тасвирлау

Мәдәният учреждениеләренең эше, беренче чиратта, халыкның мәдәни ялының дәрәҗәсен күтәрүгә, милли традицияләрне саклауга, иҗади коллективларның мәдәни-эстетик һәм сәнгать дәрәҗәсен күтәрүгә, яңа мөмкинлекләр эзләүгә юнәлтелгән.

Халык иҗатын, сәнгатьне торгызу, саклау һәм үстерү мөһимлеге аның кешенең рухи дөньясына йогынтысы белән аңлатыла. Халык мәдәниятен саклау турында кайгыртып, без кешеләрдә үз халкыбыз белән горурлану хисен формалаштырабыз, безгә кадәрге буыннар тарафыннан эшләнгән әхлакый нормаларны саклыйбыз. Соңгы вакытта милли хисләрне нығытуда аның әһәмияте артты.

Мәдәниятне, аның матди һәм рухи кыйммәтләрен саклау һәм үстерү проблемасы безнең көннәрдә дә актуаль булып кала. Без теләсә кайсы халыкның мәдәниятен сакларга, аның үсешенә ярдәм итәргә тиеш. Традицион халык культурасы хәзерге заман мәдәниятенең төрле юнәлешләренең, төрләренең һәм формаларының нигезен тәшкил итә.

2020 елда мәдәният учреждениеләрен тоту һәм үстерү өчен муниципаль бюджеттан 123471,1 мең сум акча бүлеп бирелде. Муниципаль мәдәният учреждениеләренең үз керемнәре күләме 2728,3 мең сум тәшкил итте.

2020 елда коронавирус пандемиясе белән бәйле рәвештә мәдәният учреждениеләре тамашачылар өчен 30 апрельдән 17 августка кадәр ябылды, шулай да алар үз эшчәнлекләрен туктатмады, дистанцион формада эшләде: онлайн концертлар трансляцияләнде, лекцияләр һәм мастер-класслар, тематик киночаралар, экскурсияләр, күргәзмәләр, экспонатлар күрсәтелде, чаралар үткәрелде.

Учреждениеләр өчен 2434,0 мең сумлык музыкаль-сәхнә җиһазлары, сәхнә киемнәре, техник чаралар, 349,0 мең сумлык музыка кораллары сатып алынды, республика бюджетыннан безгә 519,7 мең сум акча бирелде. “Энергетик” Мәдәният сарае коллективлары даими рәвештә республикада һәм аннан читтә үткәрелә торган төрле конкурсларга, фестивальләргә һәм чараларга йөри. Шуның белән бәйле рәвештә 2019 елның декабрендә Ford Transit микроавтобусы сатып алуга 2 341,0 мең сум күләмендә өстәмә акча бүлеп бирелде.

Бүгенге көндә күп кенә авыл җирлекләренең үз клублары бар һәм бу - зур бәхет, чөнки балалар һәм өлкәннәр җәяүләп кенә иҗади секцияләргә һәм түгәрәкләргә йөрү, шулай ук зур чараларда катнашу мөмкинлегенә ия. «Авыл клублары» республика программасы буенча районда 2017 елдан башлап 50 урынга исәпләнгән 4 күпфункцияле үзәк төзелде, алар - Поповкада (бинага башкарма комитет та урнашты), Карманда, Бура Киртәдә (китапханәдә дә шул бинада) һәм Төгидә.

«Мәдәни билгеләнештәге объектларга капиталь ремонт» республика программасы кысаларында 2017 елдан Сәвәләй авылы мәдәният йорты,

шәһәр мәдәният йорты, Түбән Биш авылы мәдәният йорты, Аксар авылы мәдәният йорты ремонтланды.

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру барышында республика бюджетыннан социаль әһәмияткә ия объектларны төзекләндерү һәм ремонтлау өчен түбәндәге күләмдә средстволар бүлеп бирелде:

1. 2018 елда:
   - авыл мәдәният йортларында җылы санузелларны төзекләндерүгә һәм ремонтлауга - 778,2 мең сум;
   - «Зәй туган як тарихын өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә видеокүзәтү системасы сатып алу һәм урнаштыруга- 200,4 мең сум.
2. 2019 елда:
   - Дүрт-Мунча, Яңа Спас авыллары мәдәният йортларында җылы санузелларны төзекләндерү һәм ремонтлау өчен - 330,9 мең сум.

Ел саен мәдәният учреждениеләре Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм хәйрия оешмаларыннан грант ярдәме алуга конкурсларда катнаша. Авылның иң яхшы мәдәният хезмәткәрләре һәм иң яхшы мәдәният учреждениеләре бүләкләнә, учреждениеләр иҗат коллективларының социаль проектлары җиңү яулый. 2017 елда гомуми суммасы 450,0 мең сумлык җиде грант бирелде, алар сәхнә костюмнары сатып алуга, хезмәткәрләрне бүләкләүгә, социаль проектларны гамәлгә ашыруга тотылды. 2018 елда 228,0 мең сумлык өч грант бирелде, алар шулай ук музыкаль җиһазлар сатып алуга, хезмәткәрләрне бүләкләүгә, социаль проектларны гамәлгә ашыруга сарыф ителде. 2019 елда 300,0 мең сумлык өч грант акчасына сәхнә костюмнары сатып алынды, хезмәткәрләрне бүләкләүгә бирелде, социаль проектларны тормышка ашыруга тотылды. 2020 елда откан өч грантның суммасы 250 мең тәшкил итте, аңа музыкаль җиһазлар, мебель, оргтехника сатып алынды һәм хезмәткәр акчалата бүләкләнде.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыру барышында 2014-2021 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы кысаларында муниципаль район бюджетына башка бюджетара трансфертлар (конкурс нигезендә) керү планлаштырыла:

1. «Мәдәният тармагына ярдәм (Иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләренә дәүләт ярдәме)".
2. «Мәдәният тармагына ярдәм (Иң яхшы авыл мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә дәүләт ярдәме)".
3. Китапханәләрнең китап фондын комплектлауга.
4. Модель китапханә булдыруга.

Зәй муниципаль районының мәдәният өлкәсендә ирекле (волонтерлык) һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшен стимуллаштыру һәм аларның социаль-мәдәни һәм иҗади проектларны (чараларны) гамәлгә ашыруда катнашуын тәэмин итү өчен мәгълүмати, консультация ярдәме күрсәтелергә мөмкин.

Хәзерге вакытта Зәй шәһәрендә һәм Зәй муниципаль районында 6 муниципаль мәдәният учреждениесе эшли. Мәдәният объектларының гомуми челтәре түбәндәгеләрне үз эченә ала:

«Зәй туган як тарихын өйрәнү музее» МБМУ,

«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» МБМУ 34 китапханәне үз эченә ала: С. Рәфыйков исемендәге үзәк китапханә, үзәк балалар китапханәсе, 32 – китапханә-филиалны,

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль бюджет киноучреждениесе,

ТР ЗМР «Зәй балалар музыка мәктәбе» МБУДО,

«Район мәдәният йорты» МБМУ 42 клубны үз эченә ала: район мәдәният йорты, шәһәр мәдәният йорты, 2 автоклуб, 22 авыл мәдәният йортын, 16 авыл клубын,

ТР ЗМР «Энергетик» Мәдәният сарае» МБУ.

Муниципаль китапханәләрнең үсеш алган челтәре шәһәрдә һәм районда китапханә хезмәте күрсәтүнең төп нигезе булып тора.

Заманча китапханәнең үзенчәлеге шунда ки, ул ачык, аның хезмәтеннән һәркем файдалана ала, ул мөмкин кадәр киң аудиториягә хезмәт күрсәтә, төрле катлам укучыларга йөз белән борыла, җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү үзәгенә әверелә бара.

2020 елның 1 декабренә китапханә хезмәтләреннән 25 807 укучы файдаланган. 2020 елда китап укучыларгага 515781 данә китап бирелгән. Китапханәгә йөрүчеләр саны - 344 950.

«Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе 2017 елдан бердәм китап укучылар билетын гамәлгә кертү өстендә эшли. Аның ярдәмендә китап укучылар, өйдән чыкмыйча гына, кызыксындыра торган китапны эзләү һәм броньлау мөмкинлегенә ия булачак.

Районда китапханә эшенең билгеле бер казанышлары белән беррәттән, кичектергесез игътибар һәм чаралар күрүне таләп итә торган шактый җитди проблемалар бар. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасының китапханә фонды 428709 нөсхәне үз эченә ала. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, күпчелек китапханәләрнең фондлары, нигездә, 70-80 нче елларда формалаштырылган. Хәзерге вакытта алар физик яктан таушалган гына түгел, эчтәлеге буенча да искергән. Ел саен җирле бюджеттан китапханәләрнең китап фондын комплектлауга акча бүлеп бирелә, өч ел эчендә бүлеп бирелгән акчалар күләме 600,0 мең сум тәшкил итте.

«Зәй туган як тарихын өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе – махсус учреждение, аның төп максаты булып мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне җыю, саклау, өйрәнү һәм системалаштыру, аларны музейга хас булган барлык формалар һәм методларны, шулай ук барлык төр массакүләм мәгълүмат чараларын кулланып, популярлаштыру тора.

Музейның төп бурычы - фондлар белән көндәлек җентекле эш алып бару (мәдәни һәм тарихи кыйммәтләрне җыю, исәпкә алу, өйрәнү,

системалаштыру, аларны популярлаштыру), хезмәткәрләр аерым игътибарны нәкъ менә шушы эш төренә бирәләр. 2020 ел ахырына фондларның гомуми күләме 14 105 экспонат тәшкил итә, шуларның 11 713е - төп фонд предметлары, 2 392се - фәнни-ярдәмче предметлар. Бинаның гомуми мәйданы 281,3 квадрат метр, экспозиция-күргәзмәләр өчен мәйдан 222,0 квадрат метр, фондны саклау өчен бүленгән мәйдан 21,0 квадрат метрны тәшкил итә. Барлыгы 2020 ел эчендә музей коллективы төрле чыганаклардан 50 төп фондны саклау берәмлеге һәм 17 фәнни-ярдәмче фонд туплады. 2020 елда 1756 музей предметы Россия Федерациясе Дәүләт каталогына кертелде (барлыгы – 2938).

2020 елда 55 күргәзмә оештырылды, шул исәптән:

музейда үз фондларыннан - 25,

башка фондларны җәлеп итеп - 5,

музейдан тыш - 25.

Хисап чорында музей хезмәткәрләре 7274 кешегә хезмәт күрсәтте, шул исәптән музейда – 3276, музейдан читтә – 4998.

2020 елда хезмәткәрләр музейда 208 экскурсия, шуның 29ы җәяүле, үткәрделәр, 79 фәнни консультация бирделәр, өч белем бирү программасын тормышка ашырдылар.

Шул ук вакытта музей мәйданнары җитмәү сәбәпле, музейны саклау, өйрәнү һәм комплектлау өлкәсендә хәл ителмәгән проблемалар да бар.

2020 елда мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр 7943тән артык чара үткәрде, аларда төрле социаль төркемдәге һәм яшьтәге 1064327 кеше катнашты.

Авыл мәдәният учреждениеләренең роле бәяләп бетергесез. Мәдәният йорты - авылның иҗтимагый һәм мәдәни тормышының үзәге, аралашу, халыкның иҗади сәләтләрен үстерү, онытылган халык традицияләрен һәм йолаларын саклау һәм торгызу урыны. Авыл мәдәни-ял итү учреждениесенең эш күрсәткечләре булып, һичшиксез, берләшмәләрнең эше, бәйрәмнәр оештыру һәм уздыру, иҗат коллективларының шәһәр, район һәм республика күләмендәге чараларда катнашуы тора.

Авыл мәдәният хезмәткәрләренең үзләренә генә хас үзенчәлекле проблемалары бар. Авыл клубында бер яки ике штаттагы хезмәткәр эшли, алар үз тирәсенә балаларны, яшьләрне, өлкәннәрне, яше, дине, милләтенә карамыйча, һәркемне берләштерә. Бездән соң килә торган буынга нинди мәдәният, нинди гореф-гадәтләрне тапшыру алар хезмәтенә бәйле.

Һәр клубта актуаль иҗади берләшмәләр һәм халыкның кызыксынуы буенча клуб берләшмәләре эшли, аларның гомуми саны – 473, алар 6500 кешене берләштерә.

Уңышлар белән беррәттән хәл ителергә тиешле проблемалар да бар, болар:

- квалификацияле кадрлар җитмәү;

- физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен биналарга керү мөмкинлеге булмау;

- күп кенә клубларда тавыш көчәйтү җиһазлары һәм сәхнә костюмнары җитми.

Шәһәрдә һәм районда ел саен Сабантуй, Питрау, Май чабу, Казанская, Нәүрүз, Михаил көне, Тройсын, Алма спасы, Боламык, Пасха халык бәйрәмнәре; «Театр дөньясында», «Халык йолалары хороводы», «Ачык һавадагы мәдәниятле Зәй» фестивальләре, Бөек Җиңү көненә, ТАССРның 100 еллыгына багышланган тантаналы чаралар, ел саен Шәһәр көне, Яңа ел бәйрәме, Яшьләр көне, сәнгать иҗаты ярминкәсе үткәрелә.

"Энергетик» Мәдәният сарае - муниципаль районда билгеле мәдәният һәм ял үзәге, иң якты һәм әһәмиятле вакыйгаларны уздыру урыны: шәһәр бәйрәмнәре һәм кичәләр, тантаналы очрашулар һәм халык җыелышлары, төрле дәрәҗәдәге фестивальләр, эстрада йолдызлары концертлары, Татарстан Республикасы театрлары спектакльләре, конкурслар, предприятиеләр һәм учреждениеләр үзешчәннәре концертлары Мәдәният сараенда үткәрелә. Аның эшчәнлегенең төп максаты - үзешчән сәнгать иҗатын һәм һәвәскәр берләшмәләрне үстерү, мәдәни-ял чараларын оештыру.

Халыкның мәдәни ялын оештыруда өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрдән файдалану мөмкинлеге, мәдәни тәрбия, талантларны ачыклау, мәдәният белгечләренең һөнәри үсешен арттыру, Зәй муниципаль районының халык иҗатын саклау һәм үстерү тора. Бу үткәрелә торган чараларның сыйфатын яхшыртырга һәм халыкның ялын югары дәрәҗәдә оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль бюджет киноучреждениесе район халкына кино-видео хезмәте күрсәтү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтә.

«Авыл районнары халкына кино хезмәте күрсәтү системасын видео-күчмә комплекслар белән модернизацияләү» республика программасы кысаларында киноучреждениегә бирелгән автомобиль чаралар үткәрергә һәм авыл җирлекләрендә фильмнар күрсәтергә мөмкинлек бирә.

2019 елда «Премьер-Зал кинотеатрлар челтәре» ҖЧҖ, «Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Чаллы филиалы раслаган репертуар план буенча заманча цифрлы контентларны кулланып эш итү учреждение эшчәнлегенең финанс нәтиҗәләре үсешенең уңай динамикасын күрсәтте һәм бу 4 978,0 мең сумны тәшкил итте. 2020 елның финанс нәтиҗәләре, үзизоляция вакытында кинофильмнар күрсәтүне туктатып тору сәбәпле, нибары 2078,4 мең сум тәшкил итте.

2020 елда киноучреждениедә цифрлы форматта 85 фильм, милли кинематографның 35 кинофильмы, документаль фильмнар, шулай ук социаль юнәлештәге проектлар күрсәтелде.

Киноучреждение эшчәнлегенең төп юнәлеше - илебез кинематографын пропагандалау, шул исәптән Татарстан кинематографистларының дәүләт заказы буенча төшерелгән фильмнарын

да. Агарту һәм мәдәният-белем бирү эшчәнлегенең төрле рәвешләренә дә зур игътибар бирелә.

Мәдәниятне һәм сәнгатьне саклап калу, үстерүнең актуаль бурычларын хәл итү комплекслы якын килүне, бөтен эшне заманча оештыруны, төгәл перспектив планлаштыруны таләп итә.

Әлеге программаны гамәлгә ашыру мәдәният учреждениеләре эшчәнлегендә булган кыенлыкларны җиңеп чыгарга, мәдәни мирасны сакларга һәм шәһәр-районның мәдәни потенциалын үстерү буенча максатчан эш алып барырга, мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри компетентлык дәрәҗәсен күтәрергә мөмкинлек бирәчәк. Программа интеллектуаль, иҗади, оештыру һәм финанс мөмкинлекләрен берләштерүне күздә тота.

## II. Гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын күрсәтеп, программаның төп максатлары һәм бурычлары, ярдәмче программаларның, программа чараларының исемлеге һәм кыскача тасвирламасы, шулай ук ярдәмче программалар һәм чараларның максатлары, бурычлары, нәтиҗәне бәяләү индикаторларыннан чыгып

Программаны эшләү өчен нигез булып Зәй муниципаль районы мәдәни мирасының, мәдәниятенең үзенчәлекле булуын аңлау, традицион мәдәниятне өйрәнү, саклау һәм торгызу буенча Зәй муниципаль районы учреждениеләре эшчәнлеген активлаштыру һәм үстерү тора. Төрле яшь категорияләрендәге кешеләрнең аралашуга, туган районның мәдәни, рухи кыйммәтләренә ихтыяҗы арта бара.

Зәй муниципаль районының социаль-икътисади үсеше максатларында мәдәният өлкәсен тотрыклы үстерү өчен кирәкле шартлар булдыру белән бергә «2021 - 2023 елларга Зәй муниципаль районында мәдәниятне үстерү» муниципаль программасының стратегик максаты булып тора:

- Мәдәният тармагын комплекслы үстерү, Зәй муниципаль районының мәдәни интеллектуаль потенциалын тормышка ашыру һәм мәдәният өлкәсендә хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту, аның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү.

Әлеге максатка ирешү өчен системалы характерга ия кайбер мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк:

1. Җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак, социо-мәдәни функцияләрне гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру максатларында, музейны комплекслы үстерү.
2. Гражданнарга аларның конституциячел хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итә торган китапханә хезмәте системасын үстерү, шулай ук китапханәләрдә саклана торган милли мәдәни мирасны саклап калу.
3. Зәй муниципаль районында киновидеофильмнарны прокатка алу һәм күрсәтү өчен кирәкле шартлар тудыру.

4. Халыкның барлык катламнары өчен мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрдән файдалану өчен уңайлы шартлар тудыру һәм халык иҗаты үсешенә ярдәм итү.

«2021-2023 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

1. Музей фондын саклау, өйрәнү һәм комплектлау.

2. Музей фондын популярлаштыру.

3. Музей тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

4. Музей эшчәнлеген мәгълүматлаштыру.

"2021-2023 елларга китапханә эшен үстерү" ярдәмче программасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

1. Китапханә фондларының актуальлеген һәм сакланышын тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы китапханә челтәренең бердәм мәгълүмат системасын үстерү.

3. Китапханәләрнең мәдәни-агарту эшчәнлеген киңәйтү.

4. Өзлексез һөнәри белем бирү һәм квалификация күтәрү системасын үстерү.

"2021-2023 елларга киноучреждениене үстерү" ярдәмче программасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

1. Тамашачы зәвыгын формалаштыру, илебез, милли, автор һәм фестиваль киносы белән кызыксынуны арттыру буенча тамашачылар белән эшләү өчен чаралар оештыру.

2. Халыкның барлык катламнары заманча кинокүрсәтү хезмәтләреннән бертигез файдалана алсын өчен шартлар тудыру.

«2021-2023 елларга мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрне үстерү һәм халык иҗатына ярдәм итү» ярдәмче программасы түбәндәгеләргә юнәлдерелгән:

1. Халыкның ялын оештыру буенча хезмәт күрсәтүләрдән бертигез файдалана алуны тәэмин итү.

2. Балалар һәм яшьләрнең иҗади потенциалын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру.

3. Мәгълүмати-методик базаны камилләштерү аша клуб учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, социаль-мәдәни өлкә белгечләренең һөнәри үсешенә ярдәм итү.

4. Халык иҗатын саклау һәм үстерү.

## III. 2021-2023 елларга Зәй муниципаль районының мәдәният өлкәсендә ирекле (волонтерлык) һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм итү

Зәй муниципаль районы территориясендә мәдәният өлкәсендә коммерцияле булмаган бер оешма – «Мәдәният өлкәсендә иҗтимагый инициативалар үзәге» мөстәкыйль коммерцияле булмаган оешма бар.

Гражданлык җәмгыяте үз мәнфәгатьләренең һәм максатларының уртаклыгын аңлау нигезендә берләшергә омтылучы һәм үз проблемаларын гына түгел, башка кешеләрнең проблемаларын да мөстәкыйль хәл итә ала торган территориядә яшәүчеләрнең ирекле үзоешуы нәтиҗәсе буларак барлыкка килә.

Бүген җәмгыять икътисадый гына түгел, ә мөһим социаль-мәдәни проблемаларны хәл итү кыенлыклары белән дә очрашты. Социаль өлкә тармагына өстәмә финанс чараларын җәлеп итү бурычларын хәл итү белән нәтиҗәле эш итәргә, шулай ук икътисад ресурсларын бүлүне оптимальләштерүгә ярдәм итәргә сәләтле институтларның берсе булып, коммерциячел булмаган сектор тора, ул шулай ук «икътисадның өченче секторы» дип атала (беренче сектордан аермалы буларак - дәүләт учреждениеләре һәм икенче сектордан аермалы буларак - эшкуарлык өлкәсе бизнес-предприятиеләре). Шуңа бәйле рәвештә, коммерциячел булмаган хуҗалык үсеше социаль өлкәне саклап калу һәм халыкны социаль яклау эшендә аеруча актуальләшә бара.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм иреклелеккә ярдәм күрсәтү җирле әһәмияткә ия мәсьәләләргә кертелгән.

Иҗтимагый берләшмәләр булганда коммерцияле булмаган оешмаларның эш сыйфаты мәсьәләсе кала. Бүгенге көндә аларның эшчәнлеге социаль характердагы бик тар даирәгә кагыла, һәм гражданлык инициативалары потенциалы тормышка ашырылган дип булмый.

Зәй муниципаль районында мәдәният өлкәсендә коммерциячел булмаган сектор үсешенең йомшак яклары булып торалар:

1. Коммерциячел булмаган оешмалар җитәкчеләрендә менеджмент һәм эш башкару өлкәсендә һөнәри һәм махсус белемнәр җитмәү һәм, нәтиҗә буларак, аларның эшчәнлегендә системалылык булмау, планлаштыруның түбән дәрәҗәсе һәм үз эшчәнлегендә программа алымын куллана белмәү.

2. Коммерциячел булмаган оешмаларның чикләнгән ресурслары – кеше, финанс, техник ресурслар.

Ирекле (волонтер) һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшен стимуллаштыру һәм аларның социаль-мәдәни һәм иҗади проектларны (чараларда) тормышка ашыруда катнашуы район территориясендә социаль-мәдәни проектларны гамәлгә ашыру һәм чараларны оештыру максатыннан мәдәният учреждениеләре белгечләре тарафыннан коммерциячел булмаган оешмаларга мәгълүмати, консультацион ярдәм күрсәтү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны тормышка ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү Зәй муниципаль районы средстволары һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына тормышка ашырыла.

Программаны тормышка ашыру өчен тотыла торган акчалар күләме ел саен бюджет үтәлеше барышында тәгаенләнә һәм 2021 – 2023 елларга бюджетны формалаштырганда исәпкә алына.

Программаны финанслауның гомуми күләме 385163,3 мең сум, шул исәптән җирле бюджеттан 367133,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 18030,0 мең сум, елларга бүлеп караганда:

– 2021 елда барысы 135121,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 129111,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 6 010,0 мең сум;

– 2022 елда барысы 127121,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 121111,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 6010,0 мең сум;

– 2023 елда барысы 122921,1 мең сум, шул исәптән: җирле бюджеттан 116911,1 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 6010,0 мең сум.

## 1. «2021-2023 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары | Ярдәмче программаның максаты - җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак, музей тарафыннан социаль-мәдәни функцияләрне гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру максатыннан, музейны комплексы үстерү.<br>Бурычлар:<br>1. Музей фондын саклау, өйрәнү һәм комплектлау.<br>2. Музей фондын популярлаштыру.<br>3. Музей тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.<br>4. Музей эшчәнлеген мәгълүматлаштыру. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2021-2023 еллар. Ярдәмче программа бер этапта гамәлгә ашырыла. |
| Елларга бүлеп һәм чыганакларын күрсәтеп, финанслау күләме | Ярдәмче программаны финанслау чыганагы булып Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар тора.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме 16461,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән җирле бюджеттан 16311,9 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 150,0 мең сум:<br>- 2021 елда барысы: 5487,3 мең сум, шул исәптән җирле бюджеттан 5437,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 50,0 мең сум;<br>- 2022 елда барысы: 5487,3 мең сум, шул исәптән җирле бюджеттан 5437,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 50,0 мең сум;<br>- 2023 елда барысы: 5487,3 мең сум, шул исәптән җирле бюджеттан 5437,3 мең сум, бюджеттан тыш чыганаклардан 50,0 мең сум.<br>Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразланган характерга ия һәм 2021-2023 елларга бюджет проектын формалаштырганда ел саен аныкланырга тиеш. |
| Программаның максатларын һәм бурычларын (нәтиҗәләрне бәяләү | Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2023 елга мөмкинлек бирәчәк:<br>- музейның дәүләт исәбенә һәм саклауга куелган төп фонды предметлары санын ел ахырына 50 берәмлеккә арттырырга; |

| | |
|---|---|
| индикаторлары) тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре һәм ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | - актив күрсәтүдә катнаша торган төп фонд предметларының төп фонд предметларының гомуми санына карата чагыштырма авырлыгын 34 процентка җиткерергә;<br>- музейга килүчеләр санын елдан-ел 6000гә кадәр арттырырга;<br>- хисап чорында музейга йөрүче гражданнарның льготалы категорияләре һәм мөмкинлекләре чикләнгән затларның нисбәтен база чорына карата 106 процентка җиткерергә;<br>- Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына кертелгән музей предметлары өлешен 30 процентка җиткерергә. |

## 1. Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы

Зәй муниципаль районы территориясендә туган як тарихын өйрәнү музее берәү генә. Музейда 2020 елның 1 декабренә төп фондның 11 713, фәнни ярдәмче фондның 2 392 предметы саклана. Музейга йөрүчеләрнең төп төркемнәре булып гаиләләр, балалар аудиториясе, яшьләр, ташламалы категориягә керүчеләр (пенсионерлар, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һ.б.) тора. Бүгенге көндә музей тарафыннан эшләнелә торган программалар һәм акцияләр күбесенчә нәкъ менә шушы максатчан төркемнәргә юнәлдерелгән.

Шәһәр һәм район халкының мәдәни кыйммәтләр белән таныша алуы музейның үзендә күргәзмәләр оештыру юлы белән генә түгел, ә бәлки күчмә күргәзмәләр, массакүләм чаралар вакытында оештырылган күргәзмәләр, Татарстан Республикасы һәм Россия музейлары белән уртак күргәзмәләр кебек эш формалары белән дә гамәлгә ашырыла. Актив күрсәтүгә җәлеп ителгән музей әйберләренең чагыштырма күләме 31% тәшкил итә.

Бүгенге көндә 2938 музей предметы Россия Федерациясенең электрон каталогына кертелгән. Мәдәни кыйммәтләрнең сакланышын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен техник чараларны, шул исәптән электрон чараларны гамәлгә кертү һәм куллану, музей фонды торышын контрольдә тотуның мөһим инструменты - чагыштыру үткәрүнең төп факторы булып тора.

Музей эшендә төп бурычларның берсе булып музей фондының сакланышын тәэмин итү тора:

1. Хәзерге вакытта янгын сигнализациясенең файдалану срогы чыга.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасын булдыруның максаты - янгынны булдырмау, кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм янгыннан милекне саклау. Янгынны булдырмас өчен кабынып

китүнең беренче 10-20 минуты мөһим булып тора. Хәбәрне вакытында җиткерү өчен янгын сигнализациясе кирәк, файдалану срогы тәмамлануга, янгыннан саклауның яңа сигнализация системасын урнаштыру зарур.

2. Фондны саклау өчен мәйданнар җитмәү.

Яңа күргәзмәләр һәм экспозицияләр ясау өчен махсус музей җиһазлары: витриналар, подиумнар таләп ителә. Музей фондны саклау өчен мәйданнарга бик каты кытлык кичерә. Моның өчен, 300 квадрат метр мәйданлы җылытылган чыгып-кереп йөрү урыны булган кызыл кирпечтән бинага ике катлы янкорма төзүне күздә тотарга кирәк. Анда экспонатларны санитар эшкәртү бүлмәсе булган фондны саклау бүлмәсе, санузел, гардероб, фонд белән эшләүчеләр өчен кабинетлар һәм күргәзмә залы урнаштыру фаразлана.

Хәл ителергә тиешле музей эшчәнлеге проблемалары:

музей фонды сакланышы,

төп фондның актив күрсәтелә торган музей әйберләрен җитәрлек дәрәҗәдә күрсәтмәү,

физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен музейга тоткарлыксыз керү мөмкинлекләре булмау (музей бинасы мәдәни мирас объекты булып тора, капиталь төзекләндерү тыела),

музей фондын цифрлы фотматка күчерү зарурлыгы.

## 2. Төп максатлар, бурычлар, программа чаралары, шулай ук ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

Ярдәмче программаның максаты - җәмгыять үсешенең мөһим ресурсы буларак, музей тарафыннан социаль-мәдәни функцияләрне гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру максатыннан, музейны комплекслы үстерү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Музей фондын саклау, өйрәнү һәм комплектлау.

2. Музей фондын популярлаштыру.

3. Музей тарафыннан мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру.

4. Музей эшчәнлеген мәгълүматлаштыру.

**2016-2020 елларда төп фондның музей әйберләрен актив күрсәтүгә җәлеп итү динамикасы**

| Ел | Төп фонд предметлары, бер. | Актив күрсәтелгән төп фонд предметлары, ед. | Актив күрсәтелгән төп фонд предметларының чагыштырма авырлыгы, % |
|---|---|---|---|
| 2017 | 11287 | 2323 | 20 |
| 2018 | 11463 | 2581 | 22 |
| 2019 | 11663 | 2956 | 25 |
| 2020 | 11713 | 3661 | 31 |

**2016-2020 елларда музейга йөрү динамикасы**

| Ел | Йөрүчеләр саны, кеше |
|---|---|
| 2016 | 3182 |
| 2017 | 2529 |
| 2018 | 2728 |
| 2019 | 5727 |
| 2020 | 3276 |

**2016-2020 елларда музейга ташламалы категориядәге гражданнар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар йөрү динамикасы**

| Ел | Йөрүчеләр саны, кеше |
|---|---|
| 2016 | 430 |
| 2017 | 551 |
| 2018 | 448 |
| 2019 | 2358 |
| 2020 | 1326 |

**2017-2020 елларда музей әйберләрен РФ дәүләт каталогына кертү динамикасы**

| Ел | Предметлар саны, бер. |
|---|---|
| 2017 | 123 |
| 2018 | 599 |
| 2019 | 460 |
| 2020 | 1756 |

**«2021-2023 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасы буенча музейның программалы чаралары исемлеге**

| П/п № | Чараның исеме | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Музей фондын саклау, өйрәнү һәм комплектлау | | | |
| | Фондны тарих һәм мәдәният әсәрләре белән тулыландыру | Ел саен | МБУК «ЗКМ», шәһәр-районда яшәүчеләр | Музейга йөрүчеләр арту |
| | Сак-янгын сигнализациясе системасын алыштыру | 2023 | Музей директоры, баш саклаучы | Музей фондының сакланышы һәм иминлеге шартларын яхшырту |
| 2 | Музей фондын популярлаштыру | | | |
| | Музей фондыннан мәдәни-белем бирү, фәнни-агарту максатларында файдалануны активлаштыру | Ел дәвамында, ел саен | Баш саклаучы | Музейга йөрүчеләр арту |
| | Реклама эшчәнлеген активлаштыру | Ел дәвамында, ел саен | Музей директоры | Музейга йөрүчеләр арту |
| 3 | Мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен музей тарафыннан мәдәни һәм фәнни-агарту, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру | | | |
| | Күргәзмә эшчәнлеген активлаштыру | Ел дәвамында, ел саен | Музей директоры | Музейга йөрүчеләр арту |
| | Музейның тематик чаралары | Ел дәвамында, ел саен | Музейның фәнни хезмәткәрләре | Музейга йөрүчеләр арту һәм мәдәни-агарту чаралары саны арту |
